**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

**№ 102** **26 июль 2018 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмә»не раслау хакында» 2013 елның 15 ноябрендәге 104 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмә»не раслау хакында» 2013 елның 15 ноябрендәге 104 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 13 мартындагы 165 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 27 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе белән җирлек бюджеты турында карар проекты даими комиссияләргә, шулай ук Совет депутатлары каравына җибәрелгәннән соң ике атна эчендә карар проекты Совет каравына чыгарыла. Җирлек бюджеты турында карар бер укылышта, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә»;

1.2. 17 пунктның 2 пунктчасы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре».

1.3. 24 пунктның 1 пунктчасы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре».

2. Рәсми басылып чыккан көненнән карар үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Югары Пәнәче авыл җирлегенең рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru/rus/verkhnepinyachinskoe.htm) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **М.Х.Туктаров**